ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.02.2022 Олы Кайбыч ав. № 78

Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле буенча планлы тикшерүнең тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле буенча планлы тикшерүнең тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын кушымтада бирелгәнчә расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе О.Д.Макаровага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 е. “17” февралендәге
78 номерлы карарына кушымта

**Форма**

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле кысаларында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге)**
( Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының 2022 е. ___________________
__ номерлы карары белән расланган)

1. Әлеге тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда планлы тикшерүләр уздырганда кулланыла.

2. Планлы тикшерү предметы әлеге тикшерү кәгазенә (контроль сорауларга) кертелгән мәҗбүри таләпләрне үтәү белән чикләнә.

3.Аңа карата планлы тикшерү уздырыла торган юридик затның исеме, шәхси эшкуарның, ИНН, ОГРН/ОГРНИП, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта): ____________________________________________________.

4. Тикшерү кәгазен тутырып, планлы тикшерү үткәрү урыны
__________________________________________________________________________

5. Планлы тикшерү үткәрү турында күрсәтмә: «___»________ , 20__ № ____.

6. Планлы тикшерү уздыручының (уздыручыларның) вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме: __________________________________________________________

7. Тикшерүнең исәп номеры һәм тикшерүләрнең бердәм реестрында исәпкә алу номерын бирү датасы: _____________________________________________________________

8. Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар исемлеге:

| N п/п | Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар исемлеге | Мәҗбүри таләпләр куелган структур берәмлекләрне күрсәтеп, норматив хокукый актларны реквизитлары | Сорауларга җавап | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | әйе | юк | Таләпләр таралмый | искәрмә |
| 1 | Тикшерелә торган юридик зат яисә индивидуаль эшкуар җир кишәрлеген билгеләнгән максатчан билгеләнеш һәм (яисә) рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә кулланамы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 7 статьясындагы 2 пункты, 42 статьясы *(1) | | | | |
| 2 | Тикшерелә торган юридик затның яисә индивидуаль эшкуарның файдаланыла торган җир кишәрлегенә Россия Федерациясе законнарында каралган хокуклары (файдаланыла торган җир кишәрлекләре, җир кишәрлекләренең өлешләре) бармы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 25 статьясындагы 1 пункты | | | | |
| 3 | «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә файдаланыла торган җир кишәрлегенә (файдаланыла торган җир кишәрлекләренең, җир кишәрлегенең бер өлеше) хокуклар теркәлгәнме яисә хокуклары чикләнү теркәлгәнме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 26 статьясындагы 1 пункты Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 8.1статьясы *(2) | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Тикшерелүче юридик зат индивидуаль эшкуары тарафыннан хокук бирү документларында күрсәтелгән жир кишәрлеге мәйданының файдаланыла торган мәйдан туры киләме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 25 статьясындагы 1 пункты, 26 статьясындагы 1 пункты | | | | |
| 5 | Тикшерелә торган юридик зат, индивидуаль эшкуар файдалана торган жир кишәрлеге чикләренең борылыш нокталары нигезләмәсе, Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында күрсәтелгән җир кишәрлеге чикләренең торышы турындагы белешмәләргә туры киләме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 6 статьясындагы 3 пункты, 25 статьясындагы 1 пункты | | | | |
| 6 | жир кишәрлегенең һәм (яисә) жир кишәрлегенең бер өлешенең чүп үләннәре һәм (яисә) күпьеллык җиләк-җимеш үсентеләренә карамый торган агач-куак үсентеләре белән зарарлану факты бармы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 42 статьясы | | | | |
| 7 | Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге жир кишәрлекләреннән (жир кишәрлекләреннән) файдалану жирләрне яисә җир кишәрлекләрен файдалануга рөхсәт нигезендә мондый жирләр яисә җир кишәрлекләре чикләрендә туфракның уңдырышлы катламын бозуга китерсә, жир яисә җир кишәрлекләре рөхсәт ителгән файдалану өчен яраклы хәлгә китерелгәнме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 39.35 статьясының 1 пунктчасы, 13статьясының 5 | | | | |
| 8 | Сервитут гамәле туктатылган очракта, тикшерелә торган юридик зат, сервитут билгеләнгән шәхси эшмәкәр тарафыннан жир кишәрлеген файдалану өчен яраклы хәлгә китерү бурычы рөхсәт ителгән файдалану нигезендә башкарылганмы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 13 статьясындагы 5 пункты, 39.25 статьясындагы 1 пунктының 9 пунктчасы | | | | |
| 9 | Тикшерелә торган юридик зат (дәүләт хакимияте органыннан, җирле үзидарә органыннан, дәүләт һәм муниципаль учреждениедән (бюджет, казна, автоном), казна предприятиесеннән, үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Россия Федерациясе президентының тарихи мирас үзәгеннән тыш) жир кишәрлегеннән (жир кишәрлекләреннән) даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын жир кишәрлеген (жир кишәрлекләрен) арендалау хокукына яисә жир кишәрлеген (жир кишәрлекләрен) милек итеп алу бурычын яңадан рәсмиләштерү бурычы үтәләме? | "Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында" 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 пункты*(3) | | | | |
| 10 | Җир кишәрлеген законнарда билгеләнгән срокларда файдалануның (үзләштерүнең) мәҗбүрилеге турындагы таләп үтәлгәнме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 42 статьясы, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 284 статьясы, Россия | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Федерациясе Җир кодексының 45 статьясы 2 пункты, 1998 елның 15 апрелендәге 66-ФЗ номерлы "Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләре турында" Федераль законның 19 статьясындагы 2 өлешенең 7 пункты *(4) | | | | |

"___"______________, 20__ ел
(тикшерү кәгазен тутыру
датасы күрсәтелә)

___________________________ _____________ ______________________________
(тикшерү кәгазен тутыручы, затның вазыйфасы) (имза) (тикшерү кәгазен тутыручы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса)